КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 8 июнь г.Казань № 777

Татарстан Республикасы электрон мактау тактасына кертү турында таныклык тасвирламасын раслау хакында

Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы электрон мактау тактасы турында» 2026 елның 1 маендагы 356 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасының электрон мактау тактасы турындагы нигезләмәнең 13 пунктын үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы электрон мактау тактасына кертү турында таныклык тасвирламасын расларга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 8 июнь, 777 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы электрон мактау тактасына кертү турында таныклык тасвирламасы

Татарстан Республикасы электрон мактау тактасына кертү турында таныклык (алга таба – таныклык) горизонталь урнашкан А4 (210 × 297 мм) форматындагы акланган ялтыравыксыз кәгазь битеннән гыйбарәт.

Периметр буенча кәгазьнең алгы ягы яфрак кырыеннан 5 мм ераклыкта киңлеге 10,7 мм булган милли мотивлар ясалган өзлексез орнамент рәвешендәге декоратив орнамент рамкасы белән уратып алына, ул тышкы һәм эчке кырыйлары буенча күренеп торган почмаклы элементлар һәм юка рам сызыклары белән эшләнә; орнамент алтын фольга белән бизәлә.

Иң югары урта өлешендә орнамент рамкасының өске кырыеннан 30 мм ераклыкта алтын фольга белән бизәлә, диаметры 28,6 мм булган Татарстан Республикасы Дәүләт гербы сурәтләнә.

Татарстан Республикасы Дәүләт гербының иң югары сул ягында 7 мм биеклектәге баш хәрефләр белән алтын фольга белән бастырып ясалган «ТАНЫКЛЫК» сүзе урнаша. «Таныклык» юлыннан 5,5 мм ераклыкта аска таба 3 мм биеклектәге баш хәрефләр белән алтын фольга белән бизәлгән «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭЛЕКТРОН МАКТАУ ТАКТАСЫ» сүзләре урнаштырыла.

Татарстан Республикасы Дәүләт гербының иң югары уң ягында 7 мм биеклектәге баш хәрефләр белән алтын фольга белән бизәлгән «ТАНЫКЛЫК» сүзе урнаша. «ТАНЫКЛЫК» юлыннан 5,5 мм ераклыкта аска таба 3 мм биеклектәге баш хәрефләр белән алтын фольга белән бизәлгән «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭЛЕКТРОН МАКТАУ ТАКТАСЫ» сүзләре урнаштырыла.

Рус һәм татар төп текст блокларының өстә һәм аста 4,3 мм ераклыкта куе соры төстәге горизонталь аергыч полосалар урнаша. Полосалар тиешле текст блогының (сул һәм уң) киңлеге буенча уза, һәр блокның баш өлешен аның төп эчтәлегеннән визуаль яктан аерып тора. Барлыгы таныклыкта шундый дүрт – һәр текст блогына икешәр (рус һәм татар) полоса була.

Битнең сул ягында «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭЛЕКТРОН МАКТАУ ТАКТАСЫ» сүзләреннән 19 мм ераклыкта түбәнрәк биеклеге 2,6 мм (баш) һәм 1,8 мм (юл) булган кара төстәге хәрефләр белән текст басыла:

«В знак общественного признания высоких
профессиональных достижений и за добросовестный труд

________________________________________________________________
(фамилия, имя, отчество (при наличии))

________________________________________________________________
(наименование организации, органа)

занесен на Электронную доску почета Республики
Татарстан в ______ году.

Выражаем благодарность за достигнутые результаты
и преданность своему делу. Желаем дальнейших
профессиональных успехов и благополучия!»

Битнең уң ягында «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭЛЕКТРОН МАКТАУ ТАКТАСЫ» сүзләреннән 19 мм ераклыкта түбәнрәк биеклеге 2,6 мм (баш) һәм 1,8 мм (юл) булган кара төстәге хәрефләр белән текст басыла:

«Югары һөнәри казанышларын иҗтимагый тану йөзеннән
һәм намуслы хезмәте өчен

_______________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булган очракта))

_______________________________________________________________
(оешма, орган атамасы)

_____ елда Татарстан Республикасы Электрон мактау
тактасына кертелде.
Эшегездә ирешкән нәтиҗәләр һәм һөнәрегезгә
тугрылык өчен рәхмәт белдерәбез. Киләчәктә дә
уңышлар һәм иминлек телибез!»

Бүләкләнүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), шулай ук оешманың (органның) исеме төп текстта 3 мм биеклектәге кара төстәге баш хәрефләр белән языла һәм ярымкалын шрифт белән күрсәтелә.

Битнең аскы өлешендә бүлә торган полоса кырыеннан 11,5 мм ераклыкта уң якта QR-код урнаша, ул gordost.tatar.ru сайтына алып бара. QR-код куе соры төстә эшләнә. QR-кодтан сул якта кара төстәге 2 мм биеклектәге хәрефләр белән эшләнгән «Официальный сайт», «Рәсми сайт», «gordost.tatar.ru» сүзләре урнаша.

Кәгазьнең аскы өлешендә үзәктә Татарстан Республикасы Премьер-министрының шәхси имзасы урнаштырыла. Имзадан сул якта «Премьер-министр Республики Татарстан» һәм «Татарстан Республикасы Премьер-министры» сүзләре урнаша. Имзаның уң ягында «А.В.Песошин» дип имза таркатып языла. Сүзләр биеклеге 2,1 мм (баш) һәм 1,4 мм (юл) булган кара төстәге хәрефләр белән басыла.

Түбәнрәк урта өлештә 2,5 мм биеклектәге кара төстәге цифрлар белән эшләнгән таныклык тапшыру елы языла.

_____________________________